**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 апрелендәге 1146 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2013 елның 14 октябрендәге 9010 номерлы**
**«Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү буенча**
**муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын**
**раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 номерлы «Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 24 июлендәге 4195 номерлы, 2016 елның 6 июлендәге 2711 номерлы, 2019 елның 26 декабрендәге 4652 номерлы, 2020 елның 29 сентябрендәге 2741 номерлы, 2021 елның 2 июнендәге 1383 номерлы, 2022 елның 3 мартындагы 650 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 4318 номерлы, 2024 елның 9 апрелендәге 1423 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«бүлек – районнар администрацияләрендә муниципаль хезмәт күрсәтү эшен гамәлгә ашыра торган торак сәясәте (муниципаль хезмәтләр) бүлекләре».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**